**Б)** $CuSO_4$ һәм Zn

**В)** $HNO_3$(конц.) һәм Ag

**1)** Коңгырт газ бүленеп чыгу

**2)** Төссез газ бүленеп чыгу

**3)** Күк төстәге утырым хасил булу

**4)** Кызыл төстәге утырым хасил булу

144. Ике матдә һәм аларны аерырга ярдәм итә торган реактив арасында тәңгәллек урнаштырыгыз. Беренче баганадагы һәр элементка икенче баганадан туры килгән элементны сайлап алыгыз.

**МАТДӘЛӘР**

**А)** KCl һәм KOH

**Б)** $Zn(OH)_2$ һәм $Mg(OH)_2$

**В)** $MgSO_4$ һәм NaBr

**РЕАКТИВ**

**1)** HCl (р-р)

**2)** $CuSO_4$

**3)** NaBr

**4)** NaOH

145. Ике матдә һәм аларны аерырга ярдәм итә торган реактив арасында тәңгәллек урнаштырыгыз. Беренче баганадагы һәр элементка икенче баганадан туры килгән элементны сайлап алыгыз.

**МАТДӘЛӘР**

**А)** LiCl һәм NaOH

**Б)** $MgCl_2$ һәм NaCl

**В)** $H_2SO_4$ һәм $KNO_3$

**РЕАКТИВ**

**1)** $BaCl_2$

**2)** KOH

**3)** HBr

**4)** фенолфталеин

146. Ике матдә һәм аларны аерырга ярдәм итә торган реактив арасында тәңгәллек урнаштырыгыз.

**МАТДӘЛӘР** | **РЕАКТИВ**

**А)** HCl(эремә) һәм NaCl
**Б)** $CaCO_3$ һәм $CaSO_4$
**В)** $CuBr_2$ һәм $Cu(NO_3)_2$

**1)** Mg
**2)** $HNO_3$
**3)** $AgNO_3$
**4)** фенолфталеин

147. Ике матдә һәм аларны аерырга ярдәм итә торган реактив арасында тәңгәллек урнаштырыгыз. Беренче баганадагы һәр элементка икенче баганадан туры килгән элементны сайлап алыгыз.

**МАТДӘЛӘР** | **РЕАКТИВ**

**А)** $H_2SO_4$(эр.) һәм $Na_2SO_4$(эр.)
**Б)** $MgCl_2$ һәм NaCl
**В)** $Na_2S$ һәм NaOH

**1)** $H_2O$
**2)** KOH
**3)** HCl
**4)** Fe

148. Реакциягә керүче матдәләр һәм алар арасындагы реакция билгеләрен тәңгәлләштерегез.

**РЕАКЦИЯГӘ КЕРҮЧЕ МАТДӘЛӘР** | **РЕАКЦИЯ БИЛГЕСЕ**

**А)** $Ba(OH)_2$ һәм $HNO_3$
**Б)** $Ba(OH)_2$ һәм $H_2SO_4$
**В)** $CuSO_4$ һәм $Ba(NO_3)_2$

**1)** ак төстәге утырым хасил булу
**2)** күк төстәге утырым хасил булу
**3)** газ бүленеп чыгу
**4)** реакциянең күзгә күренерлек билгеләре юк

149. Реакциягә керүче матдәләр һәм алар арасындагы реакция билгеләрен тәңгәлләштерегез. Беренче баганадагы һәр элементка икенче баганадан туры

килгән элементны сайлап алыгыз.

| **МАТДӘЛӘР** | **РЕАКЦИЯ БИЛГЕСЕ** |
|---|---|
| **А)** $K_2SO_3$ һәм $H_2SO_4$ | **1)** газ бүленеп чыгу |
| **Б)** $HNO_3$ һәм $Zn(OH)_2$ | **2)** утырым хасил булу |
| **В)** $K_3PO_4$ һәм $AgNO_3$ | **3)** утырымның эреп бетүе |
| | **4)** реакциянең күзгә күренерлек билгеләре юк |

150. Ике матдә һәм аларны аерырга ярдәм итә торган реактив арасында тәңгәллек урнаштырыгыз. Беренче баганадагы һәр элементка икенче баганадан туры килгән элементны сайлап алыгыз.

| **МАТДӘЛӘР** | **РЕАКТИВ** |
|---|---|
| **А)** $K_2SO_3$ һәм $K_2SO_4$ | **1)** $HNO_3$ |
| **Б)** $Cu(NO_3)_2$ һәм $CuSO_4$ | **2)** $CaCO_3$ |
| **В)** $NH_4NO_3$ һәм $KNO_3$ | **3)** NaOH |
| | **4)** $BaCl_2$ |

151. Реакциягә керүче матдәләр һәм алар арасындагы реакция билгеләрен тәңгәлләштерегез. Беренче баганадагы һәр элементка икенче баганадан туры килгән элементны сайлап алыгыз.

| **МАТДӘЛӘР** | **РЕАКЦИЯ БИЛГЕСЕ** |
|---|---|
| **А)** $K_2SiO_3$ һәм $H_2SO_4$ | **1)** газ бүленеп чыгу |
| **Б)** $Cu(OH)_2$ һәм $HNO_3$ | **2)** утырым хасил булу |
| **В)** $Na_3PO_4$ һәм $AgNO_3$ | **3)** Утырымның эреп бетүе |
| | **4)** реакциянең күзгә күренерлек билгеләре юк |

152. Ике матдә һәм аларны аерырга ярдәм итә торган реактив арасында тәңгәллек урнаштырыгыз.

| **РЕАКЦИЯГӘ КЕРҮЧЕ МАТДӘЛӘР** | **РЕАКЦИЯ БИЛГЕСЕ** |
|---|---|
| **А)** $NaHCO_3$ һәм HCl(эремә) | **1)** күк төстәге утырым хасил булу |
| **Б)** $CO_2$ һәм $Ca(OH)_2$(эремә) | **2)** эремәнең тоныклануы |
| **В)** Cu һәм $H_2SO_4$(конц.) | **3)** иссез газ бүленеп чыгу |
| | **4)** зәһәр исле газ бүленеп чыгу |

153. Матдәләр бирелгән: Fe, $H_3PO_4$, $H_2SO_4$ (эремә), NaOH, $FeCl_3$, $H_2O_2$. Су һәм әлеге исемлектән генә кирәкле матдәләрне кулланып, ике стадиядә тимер (II) гидроксиды табыгыз. Үткәрелә торган реакцияләрнең билгеләрен языгыз. Ионнар алмашы реакциясе өчен реакциянең кыскартылма ионлы тигезләмәсен языгыз.

154. Матдәләр бирелгән: Fe, $NaHCO_3$, HCl(эремә), $FeSO_4$, NaOH, $H_2O_2$. Су һәм әлеге исемлектән генә кирәкле матдәләрне кулланып, ике стадиядә тимер (III) гидроксиды табыгыз. Үткәрелә торган реакцияләрнең билгеләрен языгыз. Ионнар алмашы реакциясе өчен реакциянең кыскартылма ионлы тигезләмәсен языгыз.

155. Матдәләр бирелгән: $Na_2SO_4$, $BaCl_2$, HCl, $H_2SO_4$ һәм аммиак эремәләре. Су һәм әлеге исемлектән генә кирәкле матдәләрне кулланып, ике стадиядә аммоний хлориды эремәсе табыгыз. Үткәрелә торган реакцияләрнең билгеләрен языгыз. Икенче реакция өчен реакциянең кыскартылма ионлы тигезләмәсен языгыз.

156. Матдәләр бирелгән: $AgNO_3$, $ZnSO_4$, Cu, NaOH, $H_2SO_4$ эремәсе. Су һәм әлеге исемлектән генә кирәкле матдәләрне кулланып, ике стадиядә бакыр (II) гидроксиды табыгыз. Үткәрелә торган реакцияләрнең билгеләрен языгыз. Икенче реакция өчен реакциянең кыскартылма ионлы тигезләмәсен языгыз.

157.Матдәләр бирелгән: $CaCO_3$, $H_3PO_4$, NaOH, $AgNO_3$, HCl (эремә), $Ba(NO_3)_2$. Су һәм әлеге исемлектән генә кирәкле матдәләрне кулланып, ике стадиядә кальций нитраты табыгыз. Үткәрелә торган реакцияләрнең билгеләрен языгыз. Икенче реакция өчен реакциянең кыскартылма ионлы тигезләмәсен языгыз.

158. Матдәләр бирелгән: $KNO_3$, $MgSO_4$, $BaCl_2$, KOH, NaCl. Су һәм әлеге исемлектән генә кирәкле матдәләрне кулланып, ике стадиядә калий хлориды табыгыз. Үткәрелә торган реакцияләрнең билгеләрен языгыз. Беренче реакция өчен реакциянең кыскартылма ионлы тигезләмәсен языгыз.

159. Матдәләр бирелгән: Zn, HCl (эремә), $H_3PO_4$, $AgNO_3$, $NH_4Cl$, $Ba(NO_3)_2$. Су һәм әлеге исемлектән генә кирәкле матдәләрне кулланып, ике стадиядә цинк нитраты табыгыз. Үткәрелә торган реакцияләрнең билгеләрен языгыз. Ионнар алмашы реакциясе өчен реакциянең кыскартылма ионлы тигезләмәсен языгыз.

160. Матдәләр бирелгән: Al, $H_3PO_4$, $H_2SO_4$ (эремә), $NH_3$ (эремә), $NH_4Cl$, $H_2O_2$. Су һәм әлеге исемлектән генә кирәкле матдәләрне кулланып, ике стадиядә алюминий гидроксиды табыгыз. Үткәрелә торган реакцияләрнең билгеләрен языгыз. Ионнар алмашы реакциясе өчен реакциянең кыскартылма ионлы тигезләмәсен языгыз.

161. Матдәләр бирелгән: Cu, CuO, NaCl, $AgNO_3$, HCl (эремә), $Ba(NO_3)_2$. Су һәм әлеге исемлектән генә кирәкле матдәләрне кулланып, ике стадиядә бакыр

(II) нитраты табыгыз. Үткәрелә торган реакцияләрнең билгеләрен языгыз. Икенче реакция өчен реакциянең кыскартылма ионлы тигезләмәсен языгыз.

162. Матдәләр бирелгән: Zn, $H_3PO_4$, $CuSO_4$, $Na_2SO_3$, $MgSO_4$, $Na_2S$. Су һәм әлеге исемлектән генә кирәкле матдәләрне кулланып, ике стадиядә цинк сульфиды табыгыз. Үткәрелә торган реакцияләрнең билгеләрен языгыз. Ионнар алмашы реакциясе өчен реакциянең кыскартылма ионлы тигезләмәсен языгыз.

163. Матдәләр бирелгән: $AgNO_3$, $CuSO_4$, $MgCl_2$, NaOH, $H_2SO_4$ эремәсе. Су һәм әлеге исемлектән генә кирәкле матдәләрне кулланып, ике стадиядә магний сульфаты табыгыз. Үткәрелә торган реакцияләрнең билгеләрен языгыз. Икенче реакция өчен реакциянең кыскартылма ионлы тигезләмәсен языгыз.

164. Эксперимент үткәрү өчен түбәндәге реактивлар тәкъдим ителә: Cu, $AgNO_3$, $CuCl_2$, $H_2SO_4$(эремә), NaOH, $H_2O_2$. Су һәм әлеге исемлектән генә кирәкле матдәләрне кулланып, ике стадиядә бакыр (II) гидроксиды табыгыз. Үткәрелә торган реакцияләрнең билгеләрен языгыз. Ионнар алмашы реакциясе өчен реакциянең кыскартылма ионлы тигезләмәсен языгыз.

165. Матдәләр бирелгән: $AgNO_3$, $MgSO_4$, NaCl, NaOH, $Ba(NO_3)_2$. Су һәм әлеге исемлектән генә кирәкле матдәләрне кулланып, ике стадиядә натрий нитраты эремәсе табыгыз. Үткәрелә торган реакцияләрнең билгеләрен языгыз. Икенче реакция өчен реакциянең кыскартылма ионлы тигезләмәсен языгыз.

166. Матдәләр бирелгән: Cu, CuO, $Cu(NO_3)_2$, $BaCl_2$, $H_2SO_4$ эремәсе. Су һәм әлеге исемлектән генә кирәкле матдәләрне кулланып, ике стадиядә бакыр (II) хлориды эремәсе табыгыз. Үткәрелә торган реакцияләрнең билгеләрен языгыз. Беренче реакция өчен реакциянең кыскартылма ионлы тигезләмәсен языгыз.

167. Эксперимент үткәрү өчен реактивлар тәкъдим ителә: тимер, көмеш нитраты, бакыр (II) сульфаты, тоз кислотасы һәм барий хлориды эремәләре. Шулай ук сезгә химик реакция үткәрү өчен кирәк булган лаборатория җиһазлары да бирелә.

Эксперимент үткәрү өчен кирәк булган лаборатория җиһазларын әзерләгез. Төзелгән схема нигезендә реакцияләр уздырыгыз. Үткәрелгән реакцияләр вакытында матдәләрдә күзәтелгән үзгәрешләрне тасвирлагыз. Реакциядә катнашкан матдәләрнең химик билгеләре (кислоталы-нигезле, оксидлашу-кайтару) һәм реакцияләрнең классификация билгеләре турында нәтиҗә ясагыз.

Әлеге исемлектән генә кирәкле матдәләрне кулланып, ике бер-бер артлы реакция нәтиҗәсендә тимер (II) хлориды эремәсе табыгыз. Күрсәтелгән матдәне бирә торган әверелүләр схемасын төзегез. Ике реакциянең тигезләмәсен языгыз. Ионнар алмашы реакциясе өчен кыскартылган ионлы тигезләмә языгыз.

.

168. Эксперимент үткәрү өчен реактивлар тәкъдим ителә: растворы натрий гидрокарбонаты, барий нитраты, тоз кислотасы, литий хлориды, натрий сульфаты һәм күкерт кислотасы эремәләре. Шулай ук сезгә химик реакция үткәрү өчен кирәк булган лаборатория җиһазлары да бирелә.

Әлеге исемлектән генә кирәкле матдәләрне кулланып, ике бер-бер артлы реакция нәтиҗәсендә барий сульфаты табыгыз.

Күрсәтелгән матдәне бирә торган әверелүләр схемасын төзегез. Ике реакциянең тигезләмәсен языгыз. Икенче реакция өчен кыскартылган ионлы тигезләмә языгыз.

Эксперимент үткәрү өчен кирәк булган лаборатория җиһазларын

әзерләгез. Төзелгән схема нигезендә реакцияләр уздырыгыз. Үткәрелгән реакцияләр вакытында матдәләрдә күзәтелгән үзгәрешләрне тасвирлагыз. Реакциядә катнашкан матдәләрнең химик билгеләре (кислоталы-нигезле, оксидлашу-кайтару) һәм реакцияләрнең классификация билгеләре турында нәтиҗә ясагыз.

169. Эксперимент үткәрү өчен реактивлар тәкъдим ителә: натрий хлориды, натрий гидроксиды, күкерт кислотасы, барий хлориды эремәләре, тимер (металл). Шулай ук сезгә химик реакция үткәрү өчен кирәк булган лаборатория җиһазлары да бирелә.

Әлеге исемлектән генә кирәкле матдәләрне кулланып, ике бер-бер артлы реакция нәтиҗәсендә тимер (II) хлориды эремәсе табыгыз. Күрсәтелгән матдәне бирә торган әверелүләр схемасын төзегез. Ике реакциянең тигезләмәсен языгыз. Икенче реакция өчен кыскартылган ионлы тигезләмә языгыз.

170. Эксперимент үткәрү өчен реактивлар тәкъдим ителә: күкерт кислотасы, кальций гидроксиды, кальций нитраты, барий нитраты эремләре, тимер (металл). Шулай ук сезгә химик реакция үткәрү өчен кирәк булган лаборатория җиһазлары да бирелә.

Әлеге исемлектән генә кирәкле матдәләрне кулланып, ике бер-бер артлы реакция нәтиҗәсендә тимер (II) нитраты эремәсе табыгыз. Күрсәтелгән матдәне бирә торган әверелүләр схемасын төзегез. Ике реакциянең тигезләмәсен языгыз. Икенче реакция өчен кыскартылган ионлы тигезләмә языгыз.

171. Кайсы диаграммада элементларның масса өлешләре бүленеше калий силикатының микъдари составына туры килә?

**1)**




**2)**




**3)**



**4)** 


---

172. Селтенең масса өлеше 10% булган калий гидроксиды эремәсенә артыгы белән алынган бакыр (II) нитраты эремәсе салалар. 9,8 г утырым хасил булган. Баштагы селте эремәсенең массасын исәпләгез.

173. Ике матдә һәм аларны аерырга ярдәм итә торган реактив арасында тәңгәллек урнаштырыгыз.

| **МАТДӘЛӘР** | **РЕАКТИВ** |
|---|---|
| **А)** $HNO_3$ һәм $KNO_3$ | **1)** метилоранж |
| **Б)** $K_2SO_4$ һәм $NaNO_3$ | **2)** $Zn(NO_3)_2$ |
| **В)** Ag һәм Zn | **3)** $Ba(NO_3)_2$ |
| | **4)** HBr |

174. 5,4 г массалы алюминий 219 г тоз кислотасы эремәсе белән реакциягә керә ала. Эремәдә кислотаның концентрация процентын исәпләгез.

175. Ике матдә һәм аларны аерырга ярдәм итә торган реактив арасында тәңгәллек урнаштырыгыз.

| **МАТДӘЛӘР** | **РЕАКТИВ** |
|---|---|

А) $CaCl_2$ һәм $MgSO_4$

Б) $AgNO_3$ һәм $ZnCl_2$

В) $Ba(OH)_2$ һәм NaOH

1) фенолфталеин

2) $K_2CO_3$

3) $Ba(CH_3COO)_2$

4) Fe

---

176. Матдәләр бирелгән: Cu, MgO, $CuCl_2$, NaOH, $H_3PO_4$, $H_2SO_4$ (эремә). Су һәм әлеге исемлектән генә кирәкле матдәләрне кулланып, ике стадиядә бакыр (II) оксиды табыгыз. Үткәрелә торган реакцияләрнең билгеләрен языгыз. Ионнар алмашы реакциясе өчен реакциянең кыскартылма ионлы тигезләмәсен языгыз.

177. Кайсы диаграммада элементларның масса өлешләре бүленеше кальций нитратының микъдари составына туры килә?

1) 


2) 

3)




4)




178. Кайсы диаграммада элементларның масса өлешләре бүленеше тимер (II) сульфатының микъдари составына туры килә?

1)




2)



3)




4)




179. Ике матдә һәм аларны аерырга ярдәм итә торган реактив арасында тәңгәллек урнаштырыгыз.

| **МАТДӘЛӘР** | **РЕАКТИВ** |
|---|---|
| **А)** NaF һәм NaI | **1)** $Ba(NO_3)_2$ |
| **Б)** $Mg(NO_3)_2$ һәм $LiNO_3$ | **2)** NaOH |
| **В)** KCl һәм $K_2SO_4$ | **3)** HCl |
| | **4)** $Cl_2$ |

180. Матдәләр бирелгән: MgO, $H_3PO_4$, NaCl, $AgNO_3$, HCl (эремә), $Ba(NO_3)_2$. Су һәм әлеге исемлектән генә кирәкле матдәләрне кулланып, ике стадиядә магний нитраты табыгыз. Үткәрелә торган реакцияләрнең билгеләрен языгыз. Икенче реакция өчен реакциянең кыскартылма ионлы тигезләмәсен языгыз.

181. Ике матдә һәм аларны аерырга ярдәм итә торган реактив арасында тәңгәллек урнаштырыгыз.

| **МАТДӘЛӘР** | | **РЕАКТИВ** | |
|---|---|---|---|
| **А)** | HBr(эремә) һәм $HNO_3$(эремә) | **1)** | HCl |
| **Б)** | $Al(OH)_3$ һәм $Mg(OH)_2$ | **2)** | KOH |
| **В)** | $Na_2CO_3$(эремә) һәм $Na_2SO_4$(эремә) | **3)** | $AgNO_3$ |
| | | **4)** | $BaCl_2$ |

---

182. Эксперимент үткәрү өчен түбәндәге реактивлар бирелгән: күкерт кислотасы, азот кислотасы, натрий гидроксиды, кальций хлориды, бирий хлориды, фенолфталеин эремәләре. Әлеге исемлектән генә кирәкле матдәләрне кулланып, ике бер-бер артлы реакция нәтиҗәсендә натрий хлориды эремәсе табыгыз. Үткәрелә торган реакцияләрнең билгеләрен языгыз. Икенче реакция өчен кыскартылма ионлы тигезләмә языгыз.

183. Химия лабораториясендә һәм көнкүрештә эремәләр әзерләү юллары турындагы раслаулар дөресме?

А. Кислота эремәсе әзерләү өчен концентрацияләнгән кислотага су кушарга кирәк.

Б. Бакча агачларын бөркү өчен кулланыла торган бакыр купоросы эремәсен цинкланган чиләктә сакларга ярамый.

**1)** А гына дөрес

**2)** Б гына дөрес

**3)** Ике раслау да дөрес

**4)** Ике раслау да дөрес түгел

184. Эремәләр әзерләү һәм матдәләр белән сак эш итү турындагы раслаулар дөресме?

А. Өй шартларында кислота эремәләрен (уксус, лимон һ.б. кислоталар)

алюмин савытта әзерләргә киңәш ителми.

Б. Селте эремәсе кул тиресенә эләккән очракта, янган урынны су белән юарга һәм бор кислотасы белән эшкәртергә кирәк.

1) А гына дөрес
2) Б гына дөрес
3) Ике раслау да дөрес
4) Ике раслау да дөрес түгел

185. Чиста матдәләр һәм кушылмалар турындагы раслаулар дөресме?
**А**. Диңгез суы матдәләр кушылмасыннан гыйбарәт.
**Б**. Озон чиста матдәләргә керә.

1) А гына дөрес
2) Б гына дөрес
3) Ике раслау да дөрес
4) Ике раслау да дөрес түгел

186. Чиста матдәләр һәм кушылмалар турындагы раслаулар дөресме?

А. Алюминий чиста матдәләргә керә.

Б. Төтен матдәләр кушылмасыннан гыйбарәт.

1) А гына дөрес
2) Б гына дөрес
3) Ике раслау да дөрес
4) Ике раслау да дөрес түгел

187. Лаборатория җиһазларын куллану турындагы раслаулар дөресме?

А. Тиешле масса өлешле аш тозы эремәсе әзерләү өчен үлчәү цилиндры кулланырга кирәк.

Б. Эремәдән парландыру методы белән тоз кристаллары алу өчен пробирка

кулланыла.

1) А гына дөрес
2) Б гына дөрес
3) Ике раслау да дөрес
4) Ике раслау да дөрес түгел

188. Химия лабораториясендә эшләү кагыйдәләре һәм көнкүрештә бөҗәкләр белән көрәшү өчен кулланыла торган матдәләр турында раслаулар дөресме?

А. Матдәнең исен билгеләү өчен пробирканы борынга якын китерергә һәм иснәргә кирәк.

Б. Көнкүрештә бөҗәкләргә каршы кулланыла торган аэрозольләрне ачык ут янында сибәргә ярамый.

1) А гына дөрес
2) Б гына дөрес
3) Ике раслау да дөрес
4) Ике раслау да дөрес түгел

189. Лаборатория савытларын һәм җиһазларын билгеләү турындагы раслаулар дөресме?

А. Бүлгеч бүрәнкә төрле составлы кушылмаларны фильтрлау өчен кулланыла.

Б. Ареометр эремәнең тыгызлыгын үлчәү өчен кулланыла.

1) А гына дөрес
2) Б гына дөрес
3) Ике раслау да дөрес
4) Ике раслау да дөрес түгел

190. Фильтрлау процессы һәм кеше тарафыннан химик реакцияләрнең

кулланылуы турындагы раслаулар дөресме?

А. Фильтрлау процессын тизәйтү өчен бүрәнкәнең кыеклап киселгән очын химик стакан стенасына терәп тотарга кирәк.

Б. Чуен һәм корычны эретү нигезендә оксидлашу-кайтару реакциясе ята.

1) А гына дөрес
2) Б гына дөрес
3) Ике раслау да дөрес
4) Ике раслау да дөрес түгел

191. Әйләнә-тирә мөхитнең химик матдәләр белән пычрануы һәм эремәләр әзерләү турындагы раслаулар дөресме?

А. Автомагистраль буенда үскән гөмбә һәм җиләкләрне ашарга ярый.

Б. Кислота эремәсе әзерләгәндә кислотаны суга салырга кирәк.

1) А гына дөрес
2) Б гына дөрес
3) Ике раслау да дөрес
4) Ике раслау да дөрес түгел

---

192. HCl ның масса өлеше 10% булган 146 г тоз кислотасын тулысынча нейтральләштерү өчен кирәк булган аммиак (ш.у.) күләмен исәпләгез.

193. 0,2% лы 740 г кальций гидроксиды эремәсе тарафыннан йотылган углекислый газның күләмен исәпләгез. Реакция ахырына кальций гидрокарбонатының үтә күренмәле эремәсе ($Ca(HCO_3)_2$) хасил булган.

194. Натрий гидроксидының масса өлеше 8% булган 40 г эремә аша күкертле газ үткәрәләр. Нәтиҗәдә натрий сульфиты хасил була. Реакциягә кергән газның күләмен ( ш.у.) исәпләгез.

195. Масса өлеше 10%, массасы 116,8 г булган тоз кислотасы эремәсен артыгы белән алынган магний сульфидына кушалар. Бүленеп чыккак газның күләмен (ш.у.) исәпләгез.

196. Артыгы белән алынган 730 г кальций карбонатына тоз кислотасының 20%лы эремәсе белән тәэсир иткәч бүленеп чыга торган углекислый газның күләмен (ш.у.) исәпләгез.

197. Масса өлеше 4% булган 98 г күкерт кислотасы эремәсенә артыгы белән алынган цинк салалар. Бүленеп чыккан газның күләмен (ш.у.) исәпләгез.

198. Масса өлеше 10% булган 14,6 г массалы тоз кислотасы эремәсен артыгы белән алынган кальций карбонатына кушалар. Бүленеп чыккан газның күләмен (ш.у.) исәпләгез.

199. Масса өлеше 5% булган 29,2 г массалы тоз кислотасы эремәсен артыгы белән алынган магний сульфитына кушалар. Бүленеп чыккан газның күләмен (ш.у.) исәпләгез.

200. Калий фосфатының масса өлеше 4% тәшкил иткән 106 г эремәгә артыгы белән алынган бакыр (II) хлориды эремәсе кушалар. Хасил булган утырымның массасын исәпләгез.

201. Кальций нитратының масса өлеше 5% тәшкил иткән 328 г эремәгә артыгы белән алынган натрий карбонаты эремәсе кушалар. Хасил булган утырымның массасын исәпләгез.

202. Кальций хлоридының масса өлеше 6% тәшкил иткән 370 г эремәгә артыгы белән алынган калий карбонаты эремәсе кушалар. Хасил булган утырымның массасын исәпләгез.

203. Бакыр (II) сульфатының масса өлеше 8% тәшкил иткән 300 г эремәгә артыгы белән алынган натрий гидроксиды эремәсе кушалар. Хасил булган утырымның массасын исәпләгез.

204. Бакыр (II) хлоридының масса өлеше 10% тәшкил иткән 27 г эремәгә артыгы белән алынган натрий сульфиды эремәсе кушалар. Хасил булган утырымның массасын исәпләгез.

205. Барий нитратының масса өлеше 10% тәшкил иткән 120 г эремәгә артыгы белән алынган натрий карбонаты эремәсе кушалар. Хасил булган утырымның массасын исәпләгез.

206. Көмеш нитратының масса өлеше 2% тәшкил иткән 17 г эремәгә артыгы белән алынган магний хлориды эремәсе кушалар. Хасил булган утырымның массасын исәпләгез.

207. Натрий карбонаты барлыкка килгәнче натрий гидроксидының масса өлеше 6% булган 40 г эремә аша углекислый газ үткәрделәр. Реакциягә тотылган газның күләмен (ш.у.) исәпләгез.

208. Артыгы белән алынган бакыр (II) сульфаты эремәсенә натрий гидроксидының масса өлеше 20% булган 10 г эремә кушалар. Хасил булган утырымның массасын исәпләгез.

209. Азот кислотасының масса өлеше 30% тәшкил иткән 126 г эремә аша аммиак үткәрәләр. Ул тулысынча реакциягә керә. Реакциягә кергән аммиакның күләмен (ш.у.) исәпләгез.

210. Артыгы белән алынган кальций карбонатына масса өлеше 10% булган 73 г тоз кислотасы эремәсе кушалар. Бүленеп чыккан газның күләмен (ш.у.) исәпләгез.

211. Масса өлеше 5%, массасы 252 г булган натрий сульфиты эремәсенә артыгы белән алынган тоз кислотасы эремәсе кушалар. Бүленеп чыккан газның күләмен (ш.у.) исәпләгез.

212. Масса өлеше 7% булган 350 г күкерт кислотасы эремәсе аша, аммоний сульфаты хасил булганчы, аммиак үткәрәләр. Реакциягә кергән газның күләмен (ш.у.) исәпләгез.

213. 0,448 л аммиакны (ш.у.) күкерт кислотасы аша уздырып, 66 г аммоний сульфаты эремәсе алалар. Барлыкка килгән эремәдә тозның масса өлешен исәпләгез.

214. Артыгы белән алынган магний карбонаты 146 г хлороводород эремәсе белән тәэсир итешкәч, 2,24 л углекислый газ (ш.у.) алына. Баштагы эремәдә хлороводородның масса өлешен исәпләгез.

215. Кальций гидроксиды эремәсе аша углекислый газ уздыралар. Масса өлеше 1% булган 324 г кальций гидрокарбонаты эремәсе хасил була. Реакциягә кергән газның күләмен исәпләгез.

216. 73 г тоз кислотасы эремәсен кальций карбонаты порциясе белән катнаштыралар. 0,896 л газ бүленеп чыга. Баштагы тоз кислотрасы эремәсенең масса өлешен исәпләгез.

217. Калий гидроксиды эремәсе аша 1,12 л углекислый газ (ш.у.) уздыргач, 138 г калий карбонаты эремәсе алалар. Хасил булган эремәдә тозның масса өлешен исәпләгез.

218. Калий гидроксидының масса өлеше 8% булган 28 г эремә аша калий карбонаты хасил булганчы углекислый газ үткәрәләр. Реакциягә кергән газның күләмен (ш.у.) исәпләгез.

219. Натрий гидроксиды эремәсе аша 2,24 л күкерт газы (ш.у.) уздыргач, 252 г натрий сульфиты эремәсе алалар. Хасил булган эремәдә тозның масса өлешен исәпләгез.

220. Натрий гидроксиды эремәсе аша 0,896 л күкерт газы (ш.у.) уздыргач, 63 г натрий сульфиты эремәсе алалар. Хасил булган эремәдә тозның масса өлешен исәпләгез.

221. Алюминий белән тоз кислотасы тәэсир итешкәч, 13,44 л (ш.у.) водород һәм 400 г тоз эремәсе хасил була. Хасил булган эремәдә тозның масса өлешен исәпләгез.

222. 200 г кальций хлориды эремәсенә, утырым хасил булудан туктаганчы, натрий карбонаты эремәсе кушалар. Утырымның массасы 12,0 г тәшкил итә. Баштагы эремәдә кальций хлориды эремәсенең масса өлешен исәпләгез. (Хлорның чагыштырма атом массасын 35,5 дип алыгыз).

223. 150 г натрий карбонаты эремәсенә, газ бүленеп чыгудан туктаганчы, тоз кислотасы кушалар. Барлыгы 3,36 л газ (ш.у.) бүленеп чыга. Баштагы эремәдә натрий карбонатының масса өлешен исәпләгез.

224. Натрий гидроксиды эремәсе аша 8,96 л (ш.у.) күкерт газы үткәрәләр. 400 г натрий сульфиты эремәсе хасил була. Барлыкка килгән эремәдә тозның масса өлешен исәпләгез.

225. 11,2 л (ш. у.) аммиакны 10%-лы күкерт кислотасы эремәсе аша уздыргач, уртача тоз эремәсе алалар. Баштагы күкерт кислотасы эремәсенең массасын исәпләгез.

226. Магний фосфатында фосфорның масса өлеше:

1) 23,7%
2) 35,2%
3) 47,2%
4) 70,4%

227. 175 г масса өлеше 14% булган күкерт кислотасы эремәсе аша аммоний сульфаты барлыкка килгәнче аммиак үткәрделәр. Реакциягә кергән газның күләмен (ш. у.) исәпләгез.

228. Аммоний сульфатында кислородның масса өлеше:

1) 12,1%
2) 24,2%
3) 36,4%
4) 48,5%

229. Аммоний карбонатында кислородның масса өлеше:

1) 12,5%
2) 16,6%
3) 33,3%
4) 50,0%

230. Аммоний фосфатында азотның масса өлеше:

1) 28,2%

2) 20,8%

3) 9,4%

4) 8,1%

231. Аммоний фосфатында водородның масса өлеше:

1) 0,7%

2) 2,7%

3) 8,1%

4) 9,4%

232. Кайсы диаграммада элементларның масса өлешләре бүленеше натрий сульфатының микъдари составына туры килә?

1) 


2) 

3) 


4) 


233. Кайсы диаграммада элементларның масса өлешләре бүленеше кальций сульфатының микъдари составына туры килә?

1) 


2) 

3) 


4) 


234. Кайсы диаграммада элементларның масса өлешләре бүленеше бакыр (II) нитратының микъдари составына туры килә?

1) 


2) 

3) 


4) 


235. Кайсы диаграммада элементларның масса өлешләре бүленеше аммоний фосфатының микъдари составына туры килә?

1) 


2) 

3) 


4) 


236. Эксперимент үткәрү өчен реактивлар тәкъдим ителә: аммиак, натрий хлориды, водород пероксиды, фосфор кислотасы, көмеш нитраты, тоз кислотасы эремәләре. Шулай ук сезгә химик реакция үткәрү өчен кирәк булган лаборатория җиһазлары да бирелә.

Әлеге исемлектән генә кирәкле матдәләрне кулланып, ике бер-бер артлы реакция нәтиҗәсендә көмеш хлориды табыгыз. Күрсәтелгән матдәне бирә торган әверелүләр схемасын төзегез. Ике реакциянең тигезләмәсен языгыз. Икенче реакция өчен кыскартылган ионлы тигезләмә языгыз.